# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, №3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 4 өлешендәге икенче абзацта «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан» сүзләреннән соң «казна учреждениеләре рәвешендә» сүзләрен өстәргә, «, салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда каралган салымнарны һәм җыемнарны түләгәннән соң,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Казна учреждениеләре рәвешендә төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләре, һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләре эшчәнлеген, шул исәптән коткаручыларның хокукларын һәм гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итү, шулай ук бюджет һәм автоном учреждениеләр рәвешендә төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләре, һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләре

тарафыннан дәүләт (муниципаль) йөкләмәләренең башкарылуын, шул исәптән коткаручыларның хокукларын һәм гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджет системасының тиешле бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Бюджет һәм автоном учреждениеләр рәвешендә төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләренең, һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләренең дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен башкарудан тыш гамәлгә ашырыла торган эшчәнлеген, шул исәптән коткаручыларның хокукларын һәм гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итү объектларга һәм территорияләргә хезмәт күрсәтү шартнамәләрен башкарудан керә торган акчалар исәбеннән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Башка оештыру-хокукый рәвешләрдә төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләренең, һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләренең эшчәнлеген, шул исәптән коткаручыларның хокукларын һәм гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итү уставта каралган эшчәнлекне башкару һәм Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган бүтән финанслау чыганаклары исәбеннән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы һәлакәттән коткаруның штатка кермәгән һәм иҗтимагый формированиеләре эшчәнлеген, шул исәптән коткаручыларның хокукларын һәм гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итү күрсәтелгән формированиеләрне төзегән оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр акчалары исәбеннән, шулай ук Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган бүтән финанслау чыганаклары исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

3) 15 статьяның 1 өлешендә «Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең кимендә 500 минималь күләме суммасында» сүзләрен «кимендә 20 000 сум» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 20 мае
№ 38-ТРЗ